СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 март 2026 ел г.Мензелинск № 5

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советының аерым карарларының гамәлдән чыгарылуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны кануннарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы карарын гамәлдән чыгарылган дип танырга:

- 23.08.2017 ел, № 5 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында контракт буенча муниципаль вазыйфаларны һәм Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшыру тәртибен раслау турында»;
- 11.04.2016 ел, № 2 "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында";
- 14.07.2021 ел, № 6 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының 11.04.2016 ел, №2 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәр, чыгымнар, мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр»;
- 15.02.2011 ел, № 7 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Минзәлә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характеры турында белешмәләрне Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында һәм аларның гаилә әгъзаларының

керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характеры турында белешмәләрне урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару»;

- 23.11.2012 елның №8 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы Аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына басмалар».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе А. Ф. Сәлахов